СОВЕТ
АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16.11.2022 г. Агрыз № 21-7

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 29.06.2021 елның 10-3 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Реклама турында" 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законга таянып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Салым бурычын каплау эшен оештыру турында” 30.12.2020 елның 16-54/16211 номерлы соравын исәпкә алып, "Муниципаль норматив-хокукый актта үзгәрешләр кертү турында" 13.01.2021 елның 09/13-09/49 номерлы Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы соравына, "Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурыч булмау турында норма кертергә кирәк булган муниципаль хезмәтләр күрсәтү тәртибен һәм процедурасын регламентлаучы муниципаль норматив хокукый актлар исемлеген җибәрү турында" 19.01.2021 елның 11/13-09/140 номерлы карарына, "Салым бурычларын түләү буенча эшне оештыру турында" 26.01.2021 елның 05-51/399 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы соравына, "Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставына туры китереп, муниципаль норматив хокукый актны хокукый анализ һәм законнарны мониторинглау нәтиҗәләре буенча туры китерү максатларында, Татарстан Республикасының Әгерҗе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» 29.06.2021 елның 10-3 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына кертелә торган үзгәрешләрне расларга.

2. “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 29.06.2021 елның 10-3 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәреш кертү

турында” Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының 17.08.2021 елның 11-12 номерлы карарының үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Әгерҗе районының “Татмедиа” АҖ филиалы "Әгерҗе хәбәрләре" газетасында һәм “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru), Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында урнаштырырга (http://agryz.tatarstan.ru).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советының Законлылык, регламент һәм депутат этикасы буенча Даими комитетына йөкләргә.

Муниципаль район башлыгы,
Совет Рәисе А.Р. Вәлиев

Татарстан Республикасы Әгерҗе
муниципаль районы Советының
29.06.2021 елның 10-3 номерлы
карары белән расланды
(карар редакциясендә
«16» 11 2022 №21-7)

**“Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 29.06.2021 елның 10-3 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр**

1. “Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы территориясендә тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында” 29.06.2021 елның 10-3 номерлы Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) 5 бүлекнең 5.12 пунктындагы 5.12.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.12.5. Рөхсәтне (килешүне кире алу) гамәлдән чыгару турында карар тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә шартнамә төзегән затка, 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы "Реклама турында" Федераль законның 19 статьясындагы 5 өлешендә билгеләнгән таләпләрне бозып, бирелгән очракта кабул ителә, тышкы реклама һәм мәгълүмат чараларын урнаштыру һәм эксплуатацияләү өчен күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми мөлкәте кулланыла торган очракта, "Реклама турында" 2006 елның 13 мартындагы 38-ФЗ номерлы Федераль законның 19 статьясындагы 5.1, 5.6, 5.7 өлешләре нигезендә яки аукцион яисә конкурс нәтиҗәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә яраксыз дип танылган;»;

б) 5 бүлекнең 5.9 пунктындагы 5.9.7 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.9. Россия Федерациясе бюджет системасына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу (тышкы реклама чараларын урнаштыруга һәм эксплуатацияләүгә рөхсәт алу өчен);».